Тема: **Татар теленең үз сүзләре һәм алынмалар**

***Халык сүзен безнең отасы бар,***
***Сүз түтәлен чүптән утасы бар,***
***Алтын сүзне бергә тупласы бар,***
***Кәререн белеп кенә тотасы бар.***

***З.Мәҗитов***

Сыйныф: **9**
Фән: **туган тел**

Бирем. Бирелгән җөмләгә синоним җөмләләр уйлап язызыз, бәйләүче чараларының асларына сызыгыз.

***Кайбер очракта медицина көчсез, чөнки кеше күңелен дәвалый торган даруләр әле табылмаган.***

**Килеп чыгышы ягыннан татар теленең сүзлек составы:**

1. Гомумтөрки сүзләр
2. Алынма сүзләр
3. Интернациональ сүзләр

**Гомумтөрки сүзләрнең төркемчәләре:**

1. Кешенең тән төзелешенә караган сүзләр: *баш, аяк, маңгай, каш, күз, кул, сын, арка, теш, бавыр, бугаз.*
2. Кардәшлек атамалары: *ата (әти), ана (әни), бабай.*
3. *Алмашлыклар: мин, без, син, сез, ул, алар, үз, бу.*
4. Урын, вакыт төшенчәсен белдерә торган сүзләр: *көн, төн, ел, ара, ал, арт, эч, урта, ян.*
5. Табигать күренешләре: *көн, җир, су, таш, ай, җил.*
6. Хайван, җәнлек, бөҗәк, кош-корт исемнәре: *айгыр, аю, арыслан, балык, бүре, кош, үгез, тай, ат, ау, һ.б*
7. Үсемлек исемнәре: *агач, каен һ. б.*
8. Сан белдерә торган сүзләр: *бер, ике, өч, дүрт,биш.*
9. Эш, хәрәкәт белдерә торган сүзләр: *авыру, җылау, тулу, яту, тору, яшәү, йоклау, йөрү, килү, китү, керү, үлү, туу, төшү, тору.*

- 10. Әйберләрнең, күренешләрнең сыйфатларын, үзенчәлекләрен белдерүче сүзләр: *ак, кара, ал, ач, әче, аз, күп, иске, мәңге, ялгыз, каты, сары, яшел, тере, олы.*
- 11. Тормыш-көнкүреш, ашау-эчү, хезмәт төшенчәләрен белдерә торган сүзләр: *алтын, көмеш, тимер, тамга, он, аш, азык, ил.*
- 12. Абстракт төшенчәләрне белдерүче сүзләр: *изгелек, көч, исәнлек.*
- *Бу сүзләр, бик борынгы заманнарда барлыкка килеп, төрки телләрнең күбесендә сакланып калганнар.*

## Гарәп-фарсы алынмаларының тематик бүленеше:

1. Дингә бәйле сүзләр: *Алла, дин, Ходай, Коръән, намаз, шайтан, иман, мулла һ.б.*

2. Фән һәм мәгариф өлкәсенә караган сүзләр: *гыйлем, фән, фәлсәфә, хисап, мөгаллим, мәдрәсә, дәфтәр, хикәя һ.б.*

3. Әдәбият һәм мәдәният өлкәсенә караган сүзләр: *әдип, нәшрият, мәдәният, мәдәни, мәкалә, әсәр, һ.б.*

4. Иҗтимагый-сәяси төшенчәләрне белдерә торган сүзләр: *җәмгыять, сәясәт, дәүләт, ватан, халык, һ.б.*

5. Көн исемнәре: *шимбә, якшәмбе, дүшәмбе, һ.б.*

6. Кеше исемнәре: *Габдулла, Газизә, Әхмәт, һ.б.*

7. Кыйммәтле ташларны, казылма байлыкларны белдерүче сүзләр: *алмаз, җәүһәр, якут, зөбәрҗәт һ.б.*

# Татар телендә рус алынмалары

Язма әдәби телдән кергән сүзләр татар телендә русча яңгырашны, язылышны саклап калалар: ***ракета, техника, кружка, комбайн, пенал, завод, циркуль, секундомер һ.б.***

Гади сөйләм стиле аша боынгыдан кергәннәре, татар теленең фонетик закончалыкларына буйсынып, аваз үзгәрешләре кичергәннәр: ***капуста-кәбестә, церковь-чиркәү, стол-өстәл, скамья- эскәмия, смола-сумала**, **шляпа- эшләпә, помело-пумала, канава-канау һ.б.***

# Интернациональ сүзләр

Телебездә немец, француз, инглиз, итальян, латин, грек телләреннән кергән сүзләр дә бар.

-**инглиз**: *фильм, бокс, матч, парк, хоккей, клоун, доллар, футбол, финиш;*

-**француз**: *костюм, ландшафт, бутерброд, шлагбаум;*

-**грек һәм латин**: *автор, витамин, гимн, алфавит, музей, директор, фамилия, химия, физика, биология, драма, библиотека, вирус, аттестат, фантазия;*

-**немец**: *банкрот, галстук, полиция, ракета, рейс;*

-**итальян**: *концерт, помидор, макарон, газета, валюта конфета, вермишель, салфетка һ.б.*

**Алынма сүзләрнең үзенчәлекләре:**

1. Гарәп-фарсы

- сүз башында: ***д**ан, **з**аман, **р**изык, **һ**әйкәл, **х**әтер, **ф**ән;*
- сүз башында: ***тә**рҗемә, **мә**ктәп, **мө**галлим;*
- сүз ахырында: *хөкүм**әт**, матбуг**ат**, нәшри**ят**, аш**ханә**, Үзбәк**стан***

2. Рус-европа

- сүз башында һәм сүздә: ***а**квариум, **э**кзамен, **ф**асон, ко**ф**е*;
- берничә сузык рәттән килә: *т**еа**тр, как**ао**, п**оэ**ма;*
- сүздә кушылмалар булу: *б**ю**ст, грав**ю**ра, к**ю**вет, м**ю**сли, п**ю**ре, р**ю**кзак.*

**Алынма сүзләр сингармонизмның рәт гармониясенә буйсынмый: китап, кино, телевизор**

**1.Дәреслек белән эш**

19 нчы күнегү, 22 нче бит (телдән)

Бирем: алынма сүзләрне табарга.

**2.Карточкалар буенча эш**

1 нче карточка.

Бирелгән гарәп-фарсы алынмаларын дөрес итеп язарга:

*Иг...тибар, мәг...нә, табиг...ть, сәнг...ть, г...рәп, каг...дә, кәг...зь, шиг...рь, җи...ан, сәг...ть, рә...әт, мә...әббәт, г...мер, мәк...ль, г...ләм, ...әйкәл, дә…шәт, падиша…, с…рәт, ми…нәт, ми…ербан, зә…әр, фәрм…н, әм…нәт, әхл…к.*

2 нче карточка

Бирем: гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләрнең синонимнарын язарга.

*Абруй, хәстә, нигъмәт, гаскәр, мәшһүр, шәфкать, җәмгыять, фидакяр, игълан, нәкыш, мәгълүм, фәрман, әҗәт, азат, тәмам, чор, гариза, низаг, шифа, ядкяр, ләгънәт, хәвеф-хәтәр, вәхши, мәзәк, зәгыйфь, риза, морад, пакь, сихри, файда, хәзинә, мәхәббәт, фәкыйрь, әсир*.

# Өй эше

**21 нче күнегү, 23 нче бит (язмача)**